Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2020 елның 13 ноябре, № 2

**«Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2020 елның 27 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Олыяз авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә. Олыяз авылы, Яңа урам, 11 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

2.Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2020 елның 28 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта билгеләргә. Олыяз авылы, Яңа урам, 11 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары , 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2021 елда үзара салымны 800 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Олыяз авылындагы Яңа,Тау асты урамнарындагы юлларда чокырларны ямау, вак таш җәю һәм асфальт җәю, смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

- янгын гидрантларын,җиңсәләрен,колонкаларын,стволларны сатып алу һәм урнаштыру; смета документларын төзү ;

- Тау асты урамындагы чишмә территориясен планлаштыру һәм чишмәне төзекләндерү (кыргый куакларны, агачларны кисү, чүп-чар түгү, ягулык-майлау материаллары алу, бульдозер, экскаватор эше, ком җәеп тигезләү, вак таш җәю, тутыкмый торган калайдан улак) смета документациясе төзү;

- Олыяз авылы мәдәният йорты спорт залы өчен спорт инвентаре сатып алу һәм урнаштыру (тәрәзәләр өчен сеткалар, волейбол сеткасы, волейбол һәм баскетбол туплары, эскәмияләр,теннис өстәле, күнегүләр залы җиһазлары, маталар), смета документациясе төзү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Олыяз авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Маликов

ОГРН 1021607754651
ИНН 1623001879